**Тема:*Алмашлык турында төшенчә.***(6 нчы сыйныф)
**Дәрес максаты:**
**Белем бирү максаты:** Алмашлык турында төшенчә формалаштыру, аларның әһәмиятен билгеләргә ярдәм итү;
**Фикерләү сәләтен үстерү максаты:** Укучыларның иҗади фикерләүләренә уңай йогынты ясау, үз-үзенә бәя бирү мөмкинлекләрен үстерүгә шартлар тудыру;
**Тәрбияви максат:** Туган телгә ихтирам тәрбияләүгә этәргеч ясау, аны өйрәнүгә карата җирлек тудыру.
**Дәрес тибы:**УМ кую һәм чишү.
**Предметара бәйләнешләр:** Татар әдәбияты, әйләнә-тирәне өйрәнү;
**Эш төрләре (алымнар):**сорау-җавап, карточкалар белән эш, проблемалы сорау, ребус чишү, төркемнәрдә эшләү, синквейн, күнегүләр башкару һ.б.
**Җиһазлау:** Р.Г.Хәсәншина:Татар теле дәреслеге, индивидуаль биремле карточкалар, ребус, мультимедиа проекторы, тема буенча презентация.

**Дәрес барышы:**

**I.Мотивлаштыру-ориентлашу.**
1.а)Уңай психологик халәт тудыру;
Хәерле көн, укучылар!
Кәефләрне күтәрик,
Дусларча бер елмаеп,
Бер-беребезгә
Хәерле көннәр телик!
Уң һәм сул як иптәшләрегез белән, йөзгә-йөз иптәшләрегез белән исәнләшегез.
- Бүгенге дәрестә гадәттәгечә үзегезгә үзбәя куеп барырсыз.
Ә) белемнәрне тигезләү.
-Үткән дәрестә без нинди УМ тикшердек?
Көтелгән җавап:Рәвешләрне гомумиләштереп кабатладык.
Үткән дәреснең темасын синквейн алымы белән искә төшерәбез.Үзбәя.
3.**УМ кую ситуациясе.*61 нче бирем.***
Күптән түгел **безнең** тәрәзә капкачын
Оя итте **минем** сөйгән Карлыгачым.
**Ул** көн буе аузы берлән балчык ташый,
Балчык берлән матур итеп оя ясый.
-Укучылар, бу юллар кайсы шагыйрьнеке һәм исеме ничек атала?
**Көтелгән җавап:**Габдулла Тукай “Карлыгач”

**Укытучы:** Дөрес, укучылар!Апрель ае – безгә татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайны бүләк иткән ай.Тукай бары 27 ел гына яшәгән.Укучылар, Тукайның кайсы әсәрләрен беләсез?
-Шигырьдәге билгеләнгән сүзләргә игътибар итик әле?Болар нинди сүз төркемнәре?Төркемнәрдә эшлибез, фикер алышабыз.(30 сек.)
**РЕЛЛИ РОБИН структурасы.**
**Укытучы:**Әйдәгез, искә төшерәбез, нәрсә ул сүз төркеме?
**Көтелгән җавап:** Бу бертөрле грамматик билгеләре булган сүзләр.
**Укытучы:**Димәк, билгеләнгән сүзләр нинди сүз төркеменә каравын белү өчен аның грамматик билгеләрен аерып карыйк.
**Укытучы:** бу сүзне берлек санда әйтеп карагыз.
**Көтелгән җавап:**Берлек санга куеп була.
**Укытучы:** Килеш белән төрләндереп карагыз.
**Көтелгән җавап:** Төрләнә.
**Укытучы:**Тартым белән төрләндереп карагыз.
**Көтелгән җавап:**Төрләнә.
**Укытучы:**Зат-сан белән төрләндереп карагыз.
**Көтелгән җавап:**Төрләндереп була.
**Укытучы:**Нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?
**Көтелгән җавап:**Бу сүз төркеме төрләнә.
**Укытучы:**Бу сүзгә нинди сорау куеп була?
**Көтелгән җавап:**Кем?кемнең?
**Укытучы:**Бу сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килгән?
**Көтелгән җавап:**Җөмләнең баш кисәге-ия, иярчен кисәкләре-аергыч, тәмамлык.
-Тактадагы ребусны чишик әле.Татар телендә кулланыла торган хәрефләрне сызып барыйк.Нинди сүз төркеме килеп чыгар микән?

һ **а** ә ң **лм**җ **а**ү **шлы** ө **к**

-Укучылар, әлеге сүз төркеме белән сез моңа кадәр таныш идегезме?
**Укытучы:**Димәк, без бүген алмашлык мөстәкыйль сүз төркеме турында сөйләшербез.
Сүзлектән алмашлыкның аңлатмасын карыйбыз.
Дәфтәргә тема һәм число языла.
**III. УМ өлешләп чишү.**
Укучылар , ә хәзер карточкада бирелгән текстны укып чыгыгыз.

| |
|---|
| Әмир мәктәптә бик тырышып укый.<br>Әмир- 6 нчы сыйныф укучысы.<br>Әмиргә 12 яшь.<br>Әмирнең дуслары күп. |

| |
|---|
| Әмир мәктәптә бик тырышып укый.<br>**Ул -** 6 нчы сыйныф укучысы.<br>**Аңа** 12 яшь.<br>**Аның** дуслары күп. |

- Укучылар, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр нинди сүз төркеменә карый?

- Әлеге алмашлыклар нинди сүз төркемен алмаштырып килгән?

- Ә хәзер әйтегез әле кайсы текст матуррак яңгырый? Нигә? Әлеге сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килгән?

- Димәк, укучылар, алмашлыкларның төп вазыйфасы нидән гыйбарәт?

**Модельләштерү.**

**Алмашлык**

↓

- алмаштырып килә
- җөмләдә ия, тәмамлык, аергыч
- кабатлаулардан коткара

Бергәләшеп алмашлыкның моделен языйк.Укучылар тактада яза.(30 сек)

**Дәреслек белән эш.**

- Әйдәгез, дәреслекне ачып кагыйдәне укып чыгыйк, без берни дә төшереп калдырмадыкмы икән? *(158 нче бит)*

- Димәк, алмашлык исемнәрне генә түгел, сыйфатны, сан һәм рәвешне дә алмаштырып килә торган сүз төркеме икән. Укучылар, шунсын да әйтергә кирәк алмашлыклар җөмләдә шулай ук хәбәр дә, хәл дә булып килә алалар. Моделегезне тулыландырып куегыз.

**ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН.**1.Укытучы сорау әйтә һәм уйлау өчен вакыт бирә.2. Укучылар уйлагач, җавапны кәгазьгә язалар.3.Укучылар чират буенча, җавапларны кәгазьдән укыйлар.

Бирем. Исем. Сыйфат.Бәйлек. Алмашлык.

1. Бу атамаларның уртак ягы нидә? (сүз төркемнәре)

2. Бу атамаларның кайсы артык? (бәйлек – ярдәмче сүз төркеме, ә башкалар – мөстәкыйль сүз төркеме)

3. Алмашлык мөстәкыйль сүз төркеме башка мөстәкыйль сүз төркемнәреннән нәрсә белән аерылып тора? (алмашлык - исемне, сыйфатны, сан һәм рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме)Үзбәя.

Физминут.**ТЭЙК ОФ- ТАЧ ДАУН** структурасын куллану.

Мин хәзер сүз төркемнәре әйтәм, алмашлык әйтсәм басасыз, башка сүз төркеме әйтсәм утырып каласыз.

Өстәлдәге конвертлар арасыннан 1 номерлы конвертны 2 нче номерлы укучы ача. Анда сүзләр язылган карточкалар куелган. Бирелгән сүзләр арасыннан алмашлыкларны табарга. Затын, санын, килешен билгеләргә астына сызарга. Йөзгә-йөз иптәшеңә укы.(30 сек)
Мин, ул, сезне, син, безне, энә, кайта, чыга, сиңа, су, ләкин, әкрен.Үзбәя.

2 номерлы конвертны 1 номерлы укучы ача.Бирелгән җөмләләрне языгыз һәм алмашлыкларга сорау куегыз.Аннары яныгызда парыгызның эшләрен эталон буенча тикшерегез.(1 мин)
Мине сине күтәрмен, онытма, акыллым.(М.Хөсәенов)
Мин сезгә әйттем бит, ул гаепле түгел.(Ф.Хөсни)Үзбәя.
**Бәяләү критерийлары:**
“5”- биремне үти алдым, барлык алмашлыкларга сорауларны дөрес куйдым.
“4”- бер-ике алмашлыкка сорауларны дөрес билгеләмәдем.
“3” – биремне иптәшем ярдәмендә генә үти алдым.(30 сек)
Гомуми ысулны куллану.
373 нче күнегү.Өзекләрне күчереп язарга, алмашлыкларның нинди җөмлә кисәге булуын билгеләргә.
Көтелгән җавап:1.Бу –аергыч, шушы-аергыч, аның-аергыч.
2.Сез-ия, безгә-тәмамлык.
3.Сезнең-аергыч, нинди-аергыч, ул-ия, аны-тәмамлык, безнең –аергыч, аннан- тәмамлык.
**Бу, шушы, нинди** алмашлыкларын укучылар әле белмәскә дә мөмкин.Үзбәя.

Хәзер мин сезгә бирелгән тексттан ялгызлык исемнәрен алмашлыклар белән алыштырырга тәкъдим итәм.(Текст экранда бирелә)

Гаяз беренче тапкыр мәктәпкә барды.Гаязны баскычта Наилә Якуповна каршы алды.Наилә Якуповна Гаязның букчасын күтәрергә ярдәм итте.Гаяз рәхмәт әйтте.

**Үзбәя өчен критерий:**

“5” – биремне үти алдым, барлык ялгызлык исемнәрен алмашлык белән алыштырдым.

“4” – бер-ике исемгә алмашлыкны дөрес билгеләмәдем.

“3” – биремне иптәшем ярдәмендә генә үти алдым.

- Ә хәзер, алмашлык турында бер әкият тыңлап китегез.

Борын-борын заманда алмашлыкның бер дусты да булмаган, аңа бик күңелсез, ямансу булган. Көннәрдән бер көнне ул юлга, дуслар эзләргә чыккан, атнаның һәр көнендә ул үзенә яңа дуслар тапкан, шул көннән башлап ул дусларыннан бер дә аерылмый, алар белән гел бергә икән, гел бергә булганга әлеге дусларны алмашлыкның төркемчәләре дип атаганнар.

- Әйтегез әле, укучылар, атнада ничә көн? Димәк, алмашлыкның ничә төркемчәсе бар? Дөрес, укучылар, алмашлыкның мәгънә ягыннан җиде төркемчәсе бар. Алдагы дәрестә алмашлыкның төркемчәләрен өйрәнә башларбыз.

**III.Рефлексия, бәяләү.**

-Әлеге дәрескә кадәр сез нинди сүз төркемнәрен белә идегез?

- Бүгенге дәрестә нәрсәләр белдегез?

- Сезгә дәрес файдалы булдымы?

**IV.Өйгә эш бирү.**

**Укытучы:**Сезгә 3 вариантта өй эше тәкъдим итәм.Берсен сайлап эшләгез.

(мәҗбүри) 374 нче күнегү.Алмашлыкларның асларына сызарга.

(ярым иҗади) 375 нче күнегү.Әдәби әсәрләрдән алмашлыклар кергән 5-6 җөмлә табып языгыз.

(иҗади) 376 нчы күнегү.Рәсемгә карап, җөмләләр төзеп языгыз, алмашлыклардан күбрәк файдаланырга тырышыгыз.

Дәрескә гомуми бәя кую.

- Дәрестә актив катнашуыгыз өчен рәхмәт! Дәрес тәмам, чыгарга мөмкин.